КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 декабрь г.Казань № 1335

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне куллануны билгеләү һәм бәяләү, шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының фактлагы йогынтысын бәяләү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 19 февраль, 142 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне куллануны билгеләү һәм бәяләү, шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының фактлагы йогынтысын бәяләү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне куллануны билгеләү һәм бәяләү, шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының фактлагы йогынтысын бәяләү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 19 февраль, 142 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне куллануны билгеләү һәм бәяләү, шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының фактлагы йогынтысын бәяләү тәртибенә, түбәндәге эчтәлекле 1.3 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«1.3. Мәҗбүри таләпләрне билгели торган норматив хокукый актлар нигезләмәләре йә 1 марттан, йә тиешле елның 1 сентябреннән, әмма тиешле норматив хокукый акт рәсми басылып чыккан көннән соң 90 көннән дә иртәрәк түгел, үз көченә

керергә тиеш, әгәр мәҗбүри таләпләр билгеләүне күздә тоткан федераль законда, Россия Федерациясе Президенты Указында яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә башкасы билгеләнмәгән булса.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин